**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4013**
**15.06.2021**

Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 9 декабрендәге 6589 номерлы, 2017 елның 9 июнендәге 3530 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 5760 номерлы, 2020 елның 17 августындагы 3995 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 пунктта «14 көнлек срокта» сүзләрен «биш көнлек срокта» сүзләренә алмаштырырга;

2) 17 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 15 апрелендәге 272 номерлы карары белән расланган автомобиль транспортында йөк ташу кагыйдәләре» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 21 декабрендәге 2200 номерлы карары белән расланган автомобиль транспортында йөк ташу кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 нче кушымтада «ундүрт көнлек» сүзләрен «биш көнлек» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетының Үзәк районы хакимияте Башлыгы И.Н. Галимовка, Башкарма комитетының Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма комитетының Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф. Хәбибуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов